**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ________________ КАРАР №______

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләү турында**

Россия Федерациясенең Торак кодексына, Татарстан Республикасының 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы Законына, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 апрелендәге 70 номерлы «Торак урын мәйданының исәпкә алу нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданы бирү нормасы турында»гы карарына, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына һәм Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлегенең 2026 елның 5 февралендәге 26 номерлы «Торак базарын тикшерү турында»гы хатына нигезләнеп, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмен билгеләргә:

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме: **18 624,26** сум.

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 848 543,94 сум;
1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 1 697 087,88 сум;
1.2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 2 545 631,82 сум;
1.2.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 394 175,76 сум;
1.2.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 4 242 719,70 сум;
1.2.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 5 091 263,64 сум;
1.2.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 939 807,58 сум;
1.2.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 6 788 351,52 сум.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә торакка мохтаҗлар исемлегенә кую өчен әлеге карарның 1.1. һәм 1.2. пунктларында күрсәтелгән максималь күрсәткечләрне кулланырга.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ш.Бариев

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
____________ 2026 ел, №___
кушымта

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен исәпләп чыгару**

Гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме, торак урыны сатып алу өчен ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган муниципаль берәмлекләрдә, СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәк булган гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, формула буенча билгеләнә:

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) $^{-КП}$) / (0,25 х РС),** биредә

ПД — һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ — исәп күрсәткече;

ПС-бер айга кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма) (2026 елның гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкын ипотека буенча торак кредитлау буенча уртача үлчәүле ставка елына 7,96%, ягъни 7,96/100/12=0,007 аена);

КП — кредитның гомуми түләүләр саны (айлар саны) (2026 елның гыйнварында Россия Федерациясе Үзәк банкының ипотека торак кредитлау буенча уртача үлчәүле вакыты 320 ай);

РС — гаилә әгъзалары саны;

0,7 — кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25 — кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма керемenә карата нисбәте;

"Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге" НП 05.02.2026ел, 26 номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» хаты нигезендә, 2026 елда Актаныш муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе **47 141,33** сум тәшкил итә.

## Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен исәпләү

| НП — торак урыны норма сы (кв. м) | СЖ — торак бинаны сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум.) | РС — гаилә әгъза лары ның саны (кеше ) | РЦ — 1 кв. м торак бинаның базар бәясе (сум.) | ПС - айлык кредит процент ставкасы, (уртача еллык – 7,96%) (7,96 / 100/12) | КП – кредит буенча түләүлә рнең гомуми саны (ай) | кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте | кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кеременә нисбәте (0,25*РС) | ПД – максималь керем күләме (сум) (кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 8 | 9 | 9 |
| 18 | 848 543,94 | 1 | 47 141,33 | 0,007 | 320,0 | 0,7 | 0,25 | 18 624,26 |
| 36 | 1 697 087,88 | 2 | 47 141,33 | 0,007 | 320,0 | 0,7 | 0,5 | 18 624,26 |
| 54 | 2 545 631,82 | 3 | 47 141,33 | 0,007 | 320,0 | 0,7 | 0,75 | 18 624,26 |
| 72 | 3 394 175,76 | 4 | 47 141,33 | 0,007 | 320,0 | 0,7 | 1 | 18 624,26 |
| 90 | 4 242 719,70 | 5 | 47 141,33 | 0,007 | 320,0 | 0,7 | 1,25 | 18 624,26 |
| 108 | 5 091 263,64 | 6 | 47 141,33 | 0,007 | 320,0 | 0,7 | 1,5 | 18 624,26 |
| 126 | 5 939 807,58 | 7 | 47 141,33 | 0,007 | 320,0 | 0,7 | 1,75 | 18 624,26 |
| 144 | 6 788 351,52 | 8 | 47 141,33 | 0,007 | 320,0 | 0,7 | 2 | 18 624,26 |